# КАРАР

**28 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 24 ,25 нче ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан , 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Мәмәшир авылындагы урамнарга вак таш җәю , урамнарны карап тоту , проектлау һәм смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Мәмәшир авылында автомобил юлындагы күперлләрнең бардюрларын ремонтлау һәм урнаштыру, проект сметаларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Мәмәшир авылында скважина бораулау, щит һәм автоматика белән су насосы урнаштыру, проект сметаларын эшләү һәм техник күзәтүне тормышка ашыру;
- Мәмәшир авылында су насосларын сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау, су башнясы урнаштыру, проект сметаларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Мәмәшир авылындагы чишмәләрне ремонтлау һәм саклау, проектлау һәм смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.
- янгын гидрантлары өчен компонентлар сатып алу һәм урнаштыру, проектлау һәм смета документларын эшләү һәм техник күзәтүне тормышка ашыру.
- Мәмәшир авылында урам яктырткычларын һәм урам яктыртуын көйләү өчен махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру.
- торак пункттан керү (чыгу) юлына видеокамера сатып алу һәм урнаштыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 614 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 368 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 368 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан , 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Мәмәшир авылындагы урамнарга вак таш җәю , урамнарны карап тоту , проектлау һәм смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Мәмәшир авылында автомобил юлындагы күперлэрнең бардюрларын ремонтлау һәм урнаштыру, проект сметаларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Мәмәшир авылында скважина бораулау, щит һәм автоматика белән су насосы урнаштыру, проект сметаларын эшләү һәм техник күзәтүне тормышка ашыру;

- Мәмәшир авылында су насосларын сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау, су башнясы урнаштыру, проект сметаларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Мамашир авылындагы чишмәләрне ремонтлау һәм саклау, проектлау һәм смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

- янгын гидрантлары өчен компонентлар сатып алу һәм урнаштыру, проектлау һәм смета документларын эшләү һәм техник күзәтүне тормышка ашыру.

- Мәмәшир авылында урам яктырткычларын һәм урам яктыртуын көйләү өчен махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру.

- торак пункттан керү (чыгу) юлына видеокамера сатып алу һәм урнаштыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702